Утвержден
МОБУ СОШ
им.Н.Каримова с.Кугарчи
приказом №146 от 25.08.2020 г.

**Праздник «День Знания»**

Мәктәп каршы бәйрәмчә бизәлгән. Музыка яңгырый. Алып баручы чыга.

**Розалина:** Исәнмесез хөрмәтле укытучылар, укучылар, Әти-әниләр һәм бәйрәмебезнең кунаклары! Менә кояшлы беренче сентябрь таңы безне кабат бергә җыйды. Буген мәктәпләрдә һәр бала көтеп алган, кызыклы вакыйгаларга бай булган яңа уку елы башлана. Күңелләрдә сөенеч, йөзләрдә шатлыклы елмаю балкый. Яңа уку елы һәркемгә шатлык-сөенечләр, бары тик «4»ле һәм «5»леләр генә алып килсен. Бәйрәм белән сезне , дуслар!

**Назгуль:** Шушы бәйрәмгә багышланган тантаналы линейканы ачык дип белдерәм.
*(Гимн яңгырый).*

**Розалина:** Шулай ук сезнең каршыгызда безнең чыгарылыш класс укучылары һәм нәни дусларыбыз, 1 нче класс укучылары. Әйдәгез, аларны сәламлик!

**Назгуль:** Хәзер сүз мәктәп директоры  ЮлдашбаевФаниль Яхъяулына  бирелә. Рәхим итегез!

**___________:** Сүз (*килгән кунакка)*бирелә.

**___________:** Сүз (*килгән кунакка)*бирелә.

**Назгуль: Сү**з – бэлэкэс  дусларга.

(*Сүз беренче класс укучыларына бирелә.)*

____________ Сүз  11 класс укучыларына бирелә.
**11нче класс укучылары сөйли:**
**Амина:**
1) Үтте синдә бала чагым,
Үсмер чагым – гүзәл чак!
Ул вакытның мизгелләре
Йөрәкләрә калачак.
**Илюза:**
2) Һәрвакытта якты кояш,
Серле йолдыз булдың син.
Шул кояшың, йолдызларың
Беркайчанда сүнмәсен.
**Лейсан :**
3) Чәчләреңә кунган ак күбәләк,

Шатлык очкыннары йөзеңдә.
Ак алъяпкыч, ак чәчәкләр белән
Күбәләккә охшаш үзең дә.
**Лиана :**
4) Ашкына да, талпына да бүген
Леп-леп типкән нәни йөрәгең.
Озатасың, изгеләрдән изге
Сабыйлыкның соңгы көннәрен.
**Лилия :**

5) Җуелмаслык хәтирәләр калыр
Мәктәптәге тәүге көнеңнән.
Иң башына кара йөген дә бар –
Син җаваплы кеше бүгеннән.

*(Беренче класс укучылары каршына ачкыч белән **Илюза** чыга)*

Нәни дусларыбыз! Сезгә үзебездән мирас итеп «Белем йорты» ачкычын тапшырабыз. Әлеге ачкыч сезгә Белем иленә юл күрсәтүче, киңәш бирүче булсын.

Авыр вакытларыгызда
Ачкыч ярдәмгә киллер,
Гаҗәеп Белем иленә
Ул сезне алып керер.

*(Ачкычны тапшыра).*

**Амина :**
Җир йөзендә төрле илдә
Никадәрле китап бар!
Безнең өчен һәрберсе
Бик кадерле бит алар.
**Лейсан :**
Әмма барлык китапларның
Иң беренче баскычы,
Күңелләргә тәүге булып
Белемгә юл ачучы,
Тик бер китап. Аңа тиндәш
Нинди китап бар тагын?
Беләмсез, ул нинди китап?

**1нче класс укучылары:** Ул – Әлифба китабы.

*(11нче класс укучлары беренче класс укучыларына «Әлифба» китабы тапшыра).*

**Лиана :**

Мәктәп бусагасын атлап керү белән, безне кулыбыздан тотып, Белем иленә җитәкләп баручы изге жанлы, керсез күңелле укытучылар! Сез безгә йөрәк җылыгызны биреп, күңелегездәге бар яхшылыкны бүләк итеп, язмышыбыз өчен борчылып олы тормыш юлына озатып каласыз.

**Лилия :**

Ихлас рәхмәтемне әйтер өчен,
Ничек кенә табыйм сүзләрен?
Каршылагыз тагын бик күп еллар
Бүгенгедәй Белем бәйрәмен.

ЙЫР « Укытучыма»

*(Укучылар укытучыларга, килгән кунакларга чәчәк бәйләмнәре бүләк итә).*

**Алып баручы:** Шулай шул, буген илебезнең барлык төбәкләрендә балалар шаулап мәктәпләргә килделәр, бүген Белем иленә сәяхат башлана. Буген беренче класс укучылары мәктәпкә тәүге адымнарын атлый, 11нченен кызлары зур сынау елын башлый. Аларга унышлар телик!

**Амина :**

Әйдә, дустым, бергә хәбәр итик,
Башлануын уку елының.
Күреп соклансыннар сихри көчен
Җиз кыңгырау чыңының.

**Лейсан :**

Яңгырыйдыр һәр төбәктә,
Көмеш кыңгырау чыңы.
Мәктәпләргә рәхим ит, син,
Өр – яңа уку елы.

***(11нче һәм беренче класс укучысы бергә кыңгырау шалтырата)***

**Назгуль:** Белем бәйәрәменә багышланган тантаналы линейканы ябык дип белдерәм!

**Розалина:** Әйдәгез дуслар, беренче класс укучылырын хәерле юл теләп, кул чабып беренче дәресләренә озатып калыйк.

*(11нче класс укучылары беренче класс укучыларын җитәкләп строй алдыннан мәктәп бинасына алып кереп китәләр)*

**Алып баручы:** Хөрмәтле укытучылар, кадерле укучылар! Быелгы уку елында алачак беренче билгегез Белем капкасы артында сезне көтә. Белеем капкасы ачык сезгә.

Рэхим итегез!